ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БУГУЛЬМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.11.2022 г. Бугульма № 393

**Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 21.09.2022 ел, №647 Указы нигезендә ( хәрби хезмәткә мобилизацияләнгән ата-аналар (законлы вәкилләре) ата-аналар түләвен туктатып тору өлешендә)Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының балалар сәламәтләндерү лагерьларында ял һәм сәламәтләндерүне оештыру һәм тәэмин итү буенча ташлама бирү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль закон, Татарстан Республикасы «Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, махсус хәрби операциядә катнашу өчен өлешчә мобилизацияләү кысаларында чакырылган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү максатларында КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының балалар савыктыру лагерьларында ялын һәм сәламәтләндерүне оештыру һәм тәэмин итү буенча ташламалар бирү өчен Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 21.09.2022 ел, №647 Указы нигезендә, 2022 елның 01 октябреннән хәрби хезмәткә мобилизацияләнгәннәрнең балаларына ташламалар бирү.

2. Бөгелмә муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пунктын үтәү максатыннан яшьләр сәясәте учреждениеләрен финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы уставында билгеләнгән тәртиптә басылып чыга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары О. А. Плехановага йөкләргә.

**А.М. Гершиков**